РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШЕМОРДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422050, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2
тел. (84362) 3-21-44

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЭМЭРДЭН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Шэмэрдэн авылы Лермонтов урамы, 2 йорт
тел. (84362) 3-21-44

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.01.2024 № 7-п

Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 6 маендагы 92-п номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге башкарма комитетының «Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 6 маендагы 92-п номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлектәге 7 пункт белән тулыландырырга:

«7. Исәп-хисап чорында хезмәт дисциплинасын бозган өчен дисциплинар һәм матди җаваплылыкка тартылган түбәндәге очракларда бухгалтерларга премияләр түләнми:

- сәбәпсез эш калдыру;
- соңга калу;
- турыдан туры җитәкченең боерыгын үтәмәү;

- алкоголь, наркотик, токсик исерек хәлдә эшкә килү;
- эш бирүченең милкен югалту яки бозу;
- билгеләнгән хезмәт нормаларын үтәмәү, йөкләмәләрне үтәү срокларын бозу.

Бухгалтерда алынмаган дисциплинар җәза булганда премия күләме 50% ка кими.

Әгәр премия түләнгәннән соң хокук бозулар ачыкланса, премиядән мәхрүм итү хокук бозулар ачыкланган исәп-хисап чорында башкарыла.».

1. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby/tatarstan.ru/shemordan адресы буенча урнаштырырга.
2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Шәмәрдән авыл
җирлеге башлыгы А.К.Валиев